**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 23 октябрь № 798

г. Казань

Аксубай муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Россия инновацион ягулык-энергетика компаниясе» ААҖнең Аксубай муниципаль районында урнашкан, Г.Ф.Әбрәрова милкендә булган 1,1332 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:03:130402:239 кадастр саны белән кадастр паспортында күрсәтелгән чикләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә күчемсез мөлкәт дәүләт кадастры документларына һәм Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\798.docx